Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

07.11.2022 ел

Менделеевск ш.

№685

Социаль файдаланудагы торак фондының
торак урыннарына наем шартнамәләре буенча
торак урыннар бирелүгә мохтаҗ
гражданнарны исәпкә кую буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламетына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 15 декабрендәге 838 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, .мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештәге кырның һәркайсын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формадагы кыр ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

1.2. 2.6.1. пунктның 11 пунктчасында текст буенча «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россиянең социаль фонды» на алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга» http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальниковка йөкләргә

Җитәкче Р.Р.Искәндәров